КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2024 ел, 18 сентябрь г.Казань № 6-2048

Татарстан Республикасында массакүләм физкультура-савыктыру хәрәкәтен популярлаштыру, халыкны актив ял итүгә, физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүгә җәлеп итү максатларында:

1. 2024 елның 21 сентябрендә Татарстан Республикасында «Татарстан кроссы – 2024» республика массакүләм ярышларын уздырырга.

2. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына:

2024 елның 21 сентябрендә, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты белән берлектә, халыкның төрле яшьтәге катламнарын массакүләм җәлеп итеп, «Милләт кроссы» бөтенроссия йөгерү көнен әзерләү һәм уздыру эшен оештырырга;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыклары белән берлектә, ярышларда катнашу өчен төрле яшьтәге халык катламнарын киң җәлеп итеп, «Татарстан кроссы – 2024» республика массакүләм ярышларын үткәрүне оештырырга.

3. Республика дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасының төрле милек рәвешләрендәге предприятиеләр һәм оешмалар җитәкчеләренә әлеге ярышларда үз хезмәткәрләренең катнашуын оештыруны тәкъдим итәргә.

4. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына әлеге ярышларны массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны оештырырга.

5. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына әлеге ярышлар үткәрелә торган урыннарда хокук тәртибен саклауны һәм иҗтимагый иминлекне тәэмин итүдә ярдәм күрсәтүне тәкъдим итәргә.

6. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин